**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«_01__» ___10___ 2024 ел.** **№ __187__**

2025 елга Азнакай муниципаль районы муниципаль берәмлеге балаларына өстәмә белем бирүнең туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисади, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлештәге мәгариф оешмаларының һәм күп профильле өстәмә белем бирү оешмаларының норматив чыгымнары турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында»гы 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Федераль законның 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешнең 11 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 30 декабрендәге 939 номерлы «Татарстан Республикасы балаларына өстәмә белем бирүнең туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисади, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлештәге мәгариф оешмаларының һәм күп профильле өстәмә белем бирү оешмаларының финанслау нормативларын исәпләү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында»гы карары һәм «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, карар бирә:

1. 2025 елга расларга:

2025 елга Азнакай муниципаль районы муниципаль берәмлеге балаларына өстәмә белем бирүнең туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисади, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлештәге мәгариф оешмаларының һәм күп профильле өстәмә белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын кушымта нигезендә;

-туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисади, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлештәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарга 0,75 күләмендә төзәтмә коэффициентын.

2. “Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Финанс - бюджет палатасы” МКУга түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

- әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын финанслауны;

- әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары гамәлдә булу чоры дәвамында хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла торган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын индексацияләү белән бер үк вакытта яңадан карауны.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче вазифаларын башкаручы,
икътисад һәм финанслар буенча җитәкче урынбасары О.Н. Газизова

Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты карарына кушымта
«_____» ________2024 № ______

**Азнакай муниципаль районы муниципаль берәмлеге балаларына өстәмә белем бирүнең туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисади, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлештәге мәгариф оешмаларының һәм күп профильле өстәмә белем бирү оешмаларының норматив чыгымнары**

| Өстәмә белем бирү программаның юнәлеше | Территориаль дислокация | Норматив чыгымнар (бер укучыга бер елга сумнарда) | | |
|---|---|---|---|---|
| | | беренче уку елы | икенче уку елы | өченче һәм аннан соңгы уку еллары |
| Сәнгать-эстетик | шәһәр җирлеге | 8 280 | 15333 | 18399 |
| | авыл җирлеге | 8680 | 16074 | 19289 |
| Физкультура-спорт | шәһәр җирлеге | 8179 | 15145 | 18174 |
| | авыл җирлеге | 8 579 | 15887 | 19064 |
| Техник иҗат | шәһәр җирлеге | 8583 | 15895 | 19074 |
| | авыл җирлеге | 8984 | 16636 | 19963 |
| Туристлык-туган якны өйрәнү | шәһәр җирлеге | 8381 | 15520 | 18624 |
| | авыл җирлеге | 8781 | 16261 | 19514 |
| Экология-биология | шәһәр җирлеге | 8381 | 15520 | 18624 |
| | авыл җирлеге | 8781 | 16261 | 19514 |
| Хәрби-патриотик | шәһәр җирлеге | 8381 | 15520 | 18624 |
| | авыл җирлеге | 8781 | 16261 | 19514 |
| Социаль-педагогик | шәһәр җирлеге | 7976 | 14771 | 17725 |
| | авыл җирлеге | 8376 | 15512 | 18614 |
| Социаль-икътисади | шәһәр җирлеге | 7976 | 14771 | 17725 |
| | авыл җирлеге | 8376 | 15512 | 18614 |
| Табигый фәнни | шәһәр җирлеге | 8381 | 15520 | 18624 |
| | авыл җирлеге | 8781 | 16261 | 19514 |